| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЛЕКАРЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕКАРЕВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 59 Лекарево авылы «14» апрель 2022 ел

**«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Лекарево авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеты турында" 16.12.2021елгы №47 карарга үзгәрешләр кертү турында**

«Алабуга муниципаль районы Лекарево авыл җирлегендә бюджет процессы турында» гы Положение нигезендә һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясына таянып, Лекарево авыл җирлеге Советы

Карар:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Лекарево авыл җирлеге Советының 2021 елның 16 декабрендәге 47 номерлы «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Лекарево авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 елларның планлы чорына бюджеты турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) 1 статьяда:
1 өлеш
1 пунктта «2 240,5» санын «2 507,7»санына алмаштырырга,
2 пунктта « 2 240,5» санын «2 773,6»санына алмаштырырга,
3 пунктта «0,0» санын «265,9»санына алмаштырырга;

3 өлеш
«2022 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Лекарево авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 3 статьяда:

2 нче кушымтаны «2022 елга Лекарево авыл җирлеге бюджетының фаразланыла торган керемнәре күләмнәре» яңа редакциядә бәян итәргә;

3) 4 статьяда:

1 өлеш

3 нче кушымтаны «2022 елга авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» яңа редакциядә бәян итәргә;

2 өлеш

4 нче кушымтаны «2022 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программа булмаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә:;

3 өлеш

5 нче кушымтаны «2022 елга бюджет чыгымнарының максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча җирлек бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлү» яңа редакциядә бәян итәргә:;

4) түбәндәге эчтәлекле 8 статья өстәргә::

"Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Лекарево авыл җирлеге бюджетыннан 2022 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертларның күләмен, әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә, бүлеп, 19,0 мең сум күләмендә расларга»;

«2022 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Лекарево авыл җирлеге бюджетыннан тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»7 нче кушымта өстәргә;

5) түбәндәге эчтәлекле 9 статья өстәргә::

«2022 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертларның күләмен, әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә, 63,5 мең сум күләмендә исәпкә алырга»;

«2022 елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы бюджетыннан җирлекләр бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар»8 нче кушымта өстәргә;

6) 8 – 11 статьяларын 10 – 13 статьялар белән санарга.

2. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

Рәисе Зарипова Л. И.